**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 декабрендәге 5286 номерлы карары**

**Казан шәһәре Совет районының Гадел Кутуй урамында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 36 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:060405:2019, 16:50:060405:2020;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы, Гадел Кутуй урамы;
- билгеләү максаты: электр челтәре хуҗалыгы объектын – җирле әһәмияттәге БКТП-6956 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясен урнаштыру;
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын билгеләү тәртибе һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартлары турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, милек хокукы җирле әһәмияттәге БКТП-6956 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясенә

карата теркәлгән (баланста булу турында 2024 елның 12 сентябрендәге 165-24/3630 номерлы белешмә).

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


6. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларда каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, алардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 декабрендәге
5286 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Совет районының Гадел Кутуй урамындагы ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе чикләре**




Масштаб 1:100
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
| --- | --- |
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:060405 | кадастр кварталы |
| 16:50:060405:2019, 16:50:060405:2020 | хокуклары чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номеры |